ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.11.2019 Казан шәһәре № 10-108/кс

2020 елга «Менделеевск муниципаль районы торак-коммуналь хуҗалыгы идарәсе» муниципаль унитар предприятиесе өчен эчәргә яраклы суга һәм агынты суларны транспортлауга тарифлар билгеләү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы «Менделеевск муниципаль районы торак-коммуналь хуҗалыгы идарәсе» муниципаль унитар предприятиесе өчен, шушы карар кушымтасы нигезендә, календарь буенча бүлеп, эчә торган суга һәм агынты суларны транспортлауга тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2020 елның 1 гыйнварыннан башлап 2020 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы «Менделеевск муниципаль районы торак-коммуналь хуҗалыгы идарәсе» муниципаль унитар предприятиесенә ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу

стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көненнән соңга калмыйча ачарга.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 27.11.2019 № 10-108/кс карарына кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы «Менделеевск муниципаль районы торак-коммуналь хуҗалыгы идарәсе» муниципаль унитар предприятиесе өчен эчә торган суга һәм агынты суларны транспортлауга 2020 елга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Техник суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | | Агынты суларны транспортлауга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр |
| | Менделеевск муниципаль районы | | | | |
| 1 | «Менделеевск муниципаль районы торак-коммуналь хуҗалыгы идарәсе» муниципаль унитар предприятиесе* | | | | |
| 1.1 | Абалач, Бәзәкә, Бөрешле, Енабердино, Камай, Монашево, Песәй, Иске Гришкино, Татар Чаллысы, Тойгуҗа, Турай авыл җирлекләре кулланучылары өчен | 22,29 | 23,18 | | |
| 1.2 | Мунай авыл җирлеге кулланучылары өчен | 36,61 | 37,06 | | |
| 1.3 | Ижевск авыл җирлеге кулланучылары өчен | 22,29 | 23,18 | 17,21 | 17,21 |

<*> Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге